# КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
Майская Горка авыл җирлеге составына Трудовой торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

2021 елның 28 октябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 28 октябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Трудовой торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, ә 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр өчен түләүләр күләме гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итүе һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү белән килешәсезме:

– Мәктәп урамы буенча тротуар һәм җәяүлеләр юлы төзүгә (тротуар өчен грунт эшләү, борт ташларын монтажлау, тротуар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

– буаны төзекләндерүгә (дамбаны ныгыту, буа төбен чүп-чардан арындыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская горка авыл җирлеге составына керүче Трудовой торак пунктында гражданнар җыенының 14.11.2019 елның 2нче номерлы карары нигезендә Трудовой торак пунктында балалар мәйданчыгын төзекләндерү өчен җыелган узара салым акчаларын, Трудовой бистәсендә буаны төзекләндерүгә юнәлтергә.

«ӘЙЕ» ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 407 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 210 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 210 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Трудовой торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.
2. «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Трудовой торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек

Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, ә 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр өчен түләүләр күләме гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итүе һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү белән килешәсезме:

– Мәктәп урамы буенча тротуар һәм җәяүлеләр юлы төзүгә (тротуар өчен грунт эшләү, борт ташларын монтажлау, тротуар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

– буаны төзекләндерүгә (дамбаны ныгыту, буа төбен чүп-чардан арындыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская горка авыл җирлеге составына керүче Трудовой торак пунктында гражданнар җыенының 14.11.2019 елның 2нче номерлы карары нигезендә Трудовой торак пунктында балалар мәйданчыгын төзекләндерү өчен җыелган үзара салым акчаларын, Трудовой бистәсендә буаны төзекләндерүгә юнәлтергә.

«ӘЙЕ» ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Майская Горка авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Майская Горка авыл җирлеге башлыгы А.П. Морозов